ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2025ел № 8854

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясе турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-695 номерлы Указы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү һәм үстерү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 45481,4 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2026 ел – 15143,03 мең сум, 2027 ел – 15162,02 мең сум, 2028 ел – 15176,35 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2025 елның 29 октябрендәге
8854 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программа эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 5 апрелендәге 40-ФЗ номерлы Федераль закон, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары:<br>яшьләр белән эшләү идарәсе,<br>җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе,<br>физик культура һәм спорт идарәсе,<br>мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе,<br>Башкарма комитетның район хакимиятләре |
| Программаның максаты | Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларны һәм һәм аларның Яр Чаллы шәһәрен социаль-икътисадый үстерүдә, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ бердәмлекне саклауда катнашуын стимуллаштыру, социаль сәясәт нәтиҗәлелеген һәм халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын күтәрү, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр балансы нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга мөлкәт, финанс, мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү механизмнарын үстерү.<br>2. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында популярлаштыру.<br>3. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга өстәмә белем бирүне үстерү, сәламәт яшәү рәвешен һәм массакүләм спортны популярлаштыру, |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүдә ярдәм күрсәтү.<br>4. Гражданнарның үз-үзләрен тотышының социаль куркыныч формаларын профилактикалауга, авыр тормыш хәлендә калган затларны социаль тернәкләндерүгә юнәлдерелгән СЮКБО эшчәнлегенә ярдәм формаларын камилләштерү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2026 - 2028 еллар<br>Тормышка ашыру этаплары билгеләнми</td></tr>
<tr><td rowspan="8">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганагы</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026 (мең сум)</td><td>2027 (мең сум)</td><td>2028 (мең сум)</td><td>Тормышка ашыруның барлык чорында (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>15143,03</td><td>15162,02</td><td>15176,35</td><td>45481,4</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>15143,03</td><td>15162,02</td><td>15176,35</td><td>45481,4</td></tr>
<tr><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруга тотыла торган акчаларның күләме Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр бюджеты, инфляция процесслары һәм икътисадый хәлнең мөмкинлекләреннән чыгып ачыкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның гомуми санынннан мөлкәти һәм финанс ярдәме алган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның өлеше арту, ел саен кимендә 10,0%<br>2. СЮКБО тарафыннан үткәрелгән чаралар һәм иҗтимагый акцияләрнең санын арттыру</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Программаны үтәүгә гомуми контрольне Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Программаны тормышка ашыру өлкәсенә характеристика, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларны тасвирлау һәм аның үсеш прогнозы

Гражданлык җәмгыяте территориядә яшәүче, мәнфәгатьләр һәм максатлар уртаклыгын аңлаган хәлдә, берләшүгә омтылучыларның һәм үз проблемаларын гына түгел, ә бәлки башка кешеләрнең проблемаларын да мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә сәләтлеләрнең ирекле рәвештә үз-үзләрен оештыру нәтиҗәсе буларак барлыкка килә.

Бүгенге көндә җәмгыять икътисадый проблемаларны хәл итү генә түгел, ә бәлки социаль-мәдәни проблемаланы хәл итүдәге кыенлыклар белән дә очрашты. Социаль өлкә тармагына өстәмә финанс средстволарын җәлеп итүгә, шулай ук икътисадый ресурсларны бүлүне оптимальләштерүгә ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итәргә сәләтле институтларның берсе булып «икътисадның өченче секторы» дип атала торган коммерцияле булмаган сектор тора. Шул сәбәпле, социаль өлкәгә ярдәм күрсәтү һәм халыкны социаль яклауны тәэмин итү эшендә коммерцияле булмаган хуҗалык итү аеруча актуальлек ала.

«2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына ярдәм күрсәтү» муниципаль программасын (алга таба – Программа) эшләү Яр Чаллы шәһәренең социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларына (алга таба – СЮКБО) ярдәм күрсәтү мәсьәләсен хәл итүгә системалы, комплекслы якын килү кирәклеге белән аңлатыла.

Программа «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 5 апрелендәге 40-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде. Программа шәһәрдә СЮКБОга ярдәм күрсәтү принциплары һәм формаларын, шулай ук СЮКБОга ярдәм күрсәтү буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели.

Әлеге Программа СЮКБОга финанс, мөлкәт, мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтүне күздә тота.

Югарыда санап үтелгәннәрдән чыгып, СЮКБО үсеше өчен шартлар тудыру җирле үзидарә органнары бурычларының берсе булырга тиеш. Шуңа күрә бу проблеманы максатчан программа юлы белән хәл итү максатка ярашлы.

СЮКБО гражданнар һәм җирле үзидарә органнары арасында кире элемтә каналы булырга, халыкта гражданлык җаваплылыгы хисе, конструктив аралашу барлыкка килүгә ярдәм итәргә тиеш.

2025 елның 1 яртыеллыгына Яр Чаллы шәһәрендә 505 коммерцияле булмаган оешма теркәлгән, алар төрле категория гражданнар белән эш алып баралар һәм халыкка социаль хезмәтләр күрсәтәләр.

2024 елда социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның Россия Федерациясе Президенты грантларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алу конкурсларында катнашуы турындагы мәсьәләләр буенча Башкарма комитет вәкилләре катнашында 27 очрашу үткәрелде.

Ел саен дүрт номинация буенча «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсы үткәрелә. 2024 елда конкурста 16 социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма катнашты. Башкарма комитетның 2024 елның 6 сентябрендәге 5756 номерлы карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсы турындагы нигезләмә нигезендә 4 җиңүче дипломнар һәм акчалата бүләк белән бүләкләнде.

2024 елда коммерцияле булмаган оешмаларның 10 проекты Россия Федерациясе Президенты грантларын бирү конкурсында җиңүче булды һәм 8,9 млн. сум күләмендә ярдәм алды.

2024 елда шәһәрдә теркәлгән 54 СЮКБО мөлкәт һәм финанс ярдәме алды.

## 3 бүлек. Программаны тормышка ашыруның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

Максат – СЮКБОны һәм һәм аларның Яр Чаллы шәһәрен социаль-икътисадый үстерүдә, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ бердәмлекне

саклауда катнашуын стимуллаштыру, социаль сәясәт нәтиҗәлелеген һәм халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын күтәрү, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр балансы нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. СЮКБОга мөлкәт, финанс, мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү механизмнарын үстерү;

2. СЮКБО эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында популярлаштыру;

3. Өстәмә белем бирүне үстерү, сәламәт яшәү рәвешен һәм массакүләм спортны популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча шәһәр чараларын үткәрүдә СЮКБОга ярдәм күрсәтү;

4. Гражданнарның үз-үзләрен тотышының социаль куркыныч формаларын профилактикалауга, авыр тормыш хәлендә калган затларны социаль тернәкләндерүгә юнәлдерелгән СЮКБО эшчәнлегенә ярдәм формаларын камилләштерү.

Программа 2026-2028 елларда тормышка ашырыла.

Муниципаль программаның этаплары билгеләнми.

## 4 бүлек. Программаның төп чаралары характеристикасы

Программа СЮКБО эшчәнлегенә ярдәм күрсәтүнең түбәндәге өстенлекле юнәлешләрен үз эченә ала:

- СЮКБОга мөлкәт, финанс, мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү;
- СЮКБО эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;
- гражданлык килешүен ныгыту, рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау, иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлеген популярлаштыру;
- гражданнарның физик, рухи-әхлакый сәламәтлеген ныгыту;
- авыр тормыш хәлендә калган яшьләргә ярдәм күрсәтү.

### Программаның индикаторлары

| Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2025 ел (база) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| Гомуми СЮКБО санынннан мөлкәт һәм финанс ярдәме алган СЮКБО өлеше, % | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| Шәһәрдә СЮКБО тарафыннан үткәрелгән чаралар һәм иҗтимагый акцияләр саны | 1170 | 1190 | 1200 | 1245 |

Исәпләү формуласы:

$$V = (A+B)/K*100,$$ монда:

А – мөлкәт ярдәме алган СЮКБОлар саны,

В – финанс ярдәме алган СЮКБОлар саны,

К – гомуми СЮКБОлар саны.

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2026-2028 елларга Программаны финанслау күләме 45481,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2026 ел – 15143,03 мең сум, 2027 ел – 15162,02 мең сум, 2028 ел – 15176,35 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмнары

Программа чараларын тормышка ашыру барышында муниципаль заказчы-координатор (Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе) төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны тормышка ашыру барышын һәм акчаларны нәтиҗәле куллануны контрольдә тота. Программа чараларын тормышка ашыру катгый рәвештә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитетның Программаны тормышка ашыруда катнашучы тармак (функциональ) органнары Программа координаторына хисап чорыннан соң киләе торган елның 15 гыйнварына кадәр аның үтәлеше турында мәгълүмат бирәләр.

Муниципаль программаларны тормышка ашыруга агымдагы мониторинг үткәрү өчен, Программаның координаторы Башкарма комитетның финанс идарәсенә һәм Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең икътисад бүлегенә ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап, нәтиҗәлелеген бәяләүне җибәрә.

## 7 бүлек. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

СЮКБО Программасын тормышка ашыру нәтиҗәсе булып СЮКБОны социаль мәсьәләләрне хәл итүгә актив рәвештә җәлеп итү, социаль сәясәтне тормышка ашыру өлкәсендә СЮБКО белән муниципаль берәмлек арасында партнерлык, актуаль иҗтимагый проблемаларны хәл итү юлларын бергәләп эзләү тора. СЮКБО белән партнерлык җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын арттыруга һәм халыкта гражданлык җаваплылыгы, хакимият белән конструктив аралашу хисе барлыкка килүгә ярдәм итәргә тиеш.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү ел саен Программаны тормышка ашыруның бөтен срогы дәвамында гамәлгә ашырыла.

8 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, программаның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2025 (база) | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максатның исеме: коммерцияле булмаган оешмаларның социаль юнәлешле эшчәнлеген һәм аларның Яр Чаллы шәһәрен социаль-икътисадый үстерүдә, иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны һәм этноконфессиональ бердәмлекне саклауда катнашуын стимуллаштыру, социаль сәясәт нәтиҗәлелеген һәм халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын күтәрү, дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр балансы нигезендә иҗтимагый килешүне тәэмин итү. | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: 1. Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга мөлкәт, финанс, мәгълүмат һәм консультация ярдәме күрсәтү механизмнарын үстерү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Патриотик тәрбия өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2028 | Чаралар саны | 5 тән ким түгел | 5 тән ким түгел | 5 тән ким түгел | 5 тән ким түгел | 14 400,0 | 14 400,0 | 14 400,0 |
| 2. | Махсус хәрби операция ветераннарына, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына социаль характердагы хезмәтләр, | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2028 | Хезмәтләр саны | 300 дән ким түгел | 300 дән ким түгел | 300 дән ким түгел | 300 дән ким түгел | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | консультацияләр, матди ярдәм, психологик ярдәм күрсәтү, аларны реабилитацияләүгә булышлык итү | | | | | | | | | | |
| 3. | Торак булмаган бүлмәләрдән түләүсез файдалану шартларында СЮКБОга мөлкәт ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе | 2026-2028 | СЮКБО саны | 46 | 46 | 46 | 46 | - | - | - |
| 4. | СЮКБОга торак булмаган бүлмәләр өчен аренда түләвеннән азат итү рәвешендә ташламалар бирү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2026-2028 | СЮКБО саны | 3 | 3 | 3 | 3 | - | - | - |
| 5. | Элемтә хезмәтләреннән файдаланган өчен чыгымнарны компенсацияләү, иҗтимагый оешмаларга коммуналь | Башкарма комитетның район хакимиятләре | 2026-2028 | Оешмалар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 493,03 | 512,02 | 526,35 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | түләүләрне түләү | | | | | | | | | |
| 6. | Дәүләт ярдәме алучы СЮКБО реестрын алып бару | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2026-2028 | СЮКБО саны | 56 | 56 | 57 | 58 | - | - | - |
| Бурычның исеме: 2. Массакүләм мәгълүмат чараларында социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлеген популярлаштыру | | | | | | | | | | | |
| 7. | Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында СЮКБО эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2026-2028 | Басмалар саны | 10 | 10 | 11 | 12 | - | - | - |
| 8. | Башкарма комитет вәкилләре белән берлектә СЮКБОның эш очрашуларын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2026-2028 | Очрашулар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - |
| 9. | «Яр Чаллы шәһәренең иң яхшы социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмасы» конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2026-2028 | Конкурслар саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 250,0 | 250,0 | 250,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: 3. СЮКБОга өстәмә белем бирүне үстерү, сәламәт яшәү рәвешен һәм массакүләм спортны популярлаштыру, балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча шәһәр чаралары үткәрүдә ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| 10. | Спорт төрләре буенча ярышларга әзерлек һәм аларны үткәрүдә СЮКБОга физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт юнәлешендә консультация һәм оештыру ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2026-2028 | Мөрәҗәгатьләр саны | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - |
| Бурычның исеме: 4. СЮКБОның гражданнарның үз-үзләрен тотуның социаль куркыныч формаларын профилактикалауга, авыр тормыш хәлендә булган затларны социаль реабилитацияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлегенә ярдәм формаларын камилләштерү | | | | | | | | | | | |
| 11. | СЮКБО ягыннан халыкның аерым төркемнәренә (наркотик кулланучыларга, мигрантларга һ.б.) социаль-психологик һәм медицина ярдәме күрсәтү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2028 | Күрсәтелгән хезмәтләр саны | 850 | 860 | 860 | 875 | - | - | - |
| 12. | Бәйлелеккә дучар булган гражданнар | Башкарма комитетның | 2026-2028 | Кеше саны | 300 | 310 | 320 | 350 | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өчен социаль-психологик хезмәтләр күрсәткәндә СЮКБОга мәгълүмат-консультация ярдәме күрсәтү | яшьләр белән эшләү идарәсе | | | | | | | | | |
| | Барлыгы: | | | | | | | | 15143,03 | 15162,02 | 15176,35 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева